Муниципальное бюджетное учреждение культуры «Бардымская централизованная библиотечная система»

# БАРДА ЯГЫ ТАРИХЫ ГЕОГРАФИК ИСЕМНӘРДӘ

## (История Бардымского района в географических названиях)

с.Барда,2013

*ПРЕДАНИЯ И МИФЫ БАРДЫМСКОГО РАЙОНА БЫЛИ СОБРАНЫ У СЕЛЬСКИХ БИБЛИОТЕКАРЕЙ БАРДЫМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА В ХОДЕ КРАЕВЕДЧЕСКОГО КОНКУРСА, ОБЪЯВЛЕННОГО ЦЕНТРОМ ЭКОЛОГИЧЕСКОЙ ИНФОРМАЦИИ ЦЕНТРАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ В 2013 ГОДУ.*

**Собрала, напечатала, отредактировала и перевела с татарского на русский язык** заведующая отделом обслуживания центральной библиотеки Шакирзянова Лилия Хамитовна .

**Материалы предоставили на конкурс библиотекари сельских библиотек района:**

Юлаева Фаниса Хамисовна –Ишимово
Тимганова Миляуша Маликовна - Новый Ашап
Камакаева Гульсира Аухатовна -Бичурино
Халилова Лидия Равилевна – Первый Краснояр
Мурсалимова Эльмира Камилевна – П Краснояр
Мустаева Люра Фаритовна – Березники
Тимганова Кадрия Ясавиевна – Сараши
Назьмукаева Милявша Мулловна – Султанай
Уразова Айгюль Гаптельмазитовна – Куземҗярово
Илькаева Розалия Шархумовна – Аклуши
Волкова Ольга Модестовна - Шермейка

**“Ак чишмә” ( суык чишмә)**

Султанай авылың төньяк - көнбатышыннан юл Куеда ягына китә. Юлның уң ягы сазлыклы, сул ягы тигезлек, ә аннан соң текә тау битләреннән тора. Сулатанайдан Куеда юлына чыгуга беренче чишмәгә юлыгасын, исеме дә “чишмә”эч. Чишмәдән соң, 1 км. чамасы үтүгә уң якта басу аша чыксаң, зур ак каен күренә. Менә шул ак каен төбеннән чишмә ага. Ак әби истәлегенә бу чишмә “Ак әби чишмәсе дип йөртелә. Ак әби: “ кем дә кем чишмәдән су алып эчә, шул кеше чишмәгә ак акча салырга тиеш, ә салмаса җәзага торыр”,- дигән. Чишмә суы бик салкын, ул давалый да, изге дә.”

*Масагутова Гульзихан сүзеннән Султанай китапхәнәче Назмукаева Миляуша язып алды. 2013 ел.*

**“Белый родник” (холодный родник)**

Дорога на северо-западе деревни Султанай ведет в сторону Куеды. Правая сторона дороги болотистая, левая – ровная , а затем крутая гористая местность. При выезде из Султаная на куединскую дорогу вначале встречаешь первый родник, это место так и называется “сторона родника”. После родника примерно через километр,если перейдешь по полю, увидишь большую белую березу. Из под этой березы вытекает другой родник, это родник хранит память о белой старушке, его так и называют “Родник белой бабушки”. Говорят, тот, кто попьет из этого родника, должен положить белую монету, а если не оставит денежку, то его постигнет несчастье. Утверждают, что вода этого родника очень холодная , да к тому же святая и лечебная.

*Со слов Масагутовой Гульзихан в 2013 году записала библиотекарь Султанаевской сельской библиотеки Назмукаева Миляуша.*

**Аклыш авылым тарихы**

Картларның сөйләүләренә караганда, Аклыш авылы моннан 300 еллар элек, 1686 нчы елларда төзелә башлаган. Ә тирә-юньдәге Үдик, Каенавыл, Озын ялан, Төнгүк һәм башка авыллар безнең авылдан 40 еллап элек урнашканнар.

Аклыш авылына Каенавылдан килгән башкорт Аклыш бабай нигез салган. Ул Сазтамак чокырыннан уң яктагы биеклеккә килеп урнашкан. Акрынлап аның тирәсенә башка авыллардан да кешеләр килеп урнаша башлаганнар. Бу авыл өчен су Сазтамак буйлап аккан, ләкин берникәдәр вакыттан соң бу су кипкән, авыл сусыз калган. Шуңа күрә авыл халкы Тол елгасы буена күченергә мәҗбур булган. Алар Тол елгасы буйлап, “Иске

йорт” дигән урынга урнашканнар. Монда да бер уңайсызлык килеп чыккан. Тол елгасы ярны җимереп авылга якынайган һәм авылны су баса башлаган. Халык, бергә кинәшеп, Аклыш елгасы буена күчкәннәр. Елганның исемен авылга нигез салучы Аклыш бабайның исеме белән атаганнар. Авыл да, кая гына күчерелсә дә, Аклыш дип йөретелгән. Хәзер яши торган авыл иң башта елганың югаргы агымыннан башланып киткән. Аннары елганың түбән агымы буйлап ике як ярга урнаша башлаганнар.

*Аклыш авылы тарихын китапханәче Илькаева Розалия Шархум кызы язып алды. 2013 ел.*

## История села Аклуши.

По рассказам сторожилов, Аклуши начали строиться 300 лет назад, в 1686 году.
А такие села как Елпачиха, Березники, Бичурино, Тюндюк повились лет на 40 раньше.

Основу Аклушам положил переехавший из Березников башкир, дед Аклыш. Он обосновался на возвышенности справа от Сазтамака. Потихоньку рядом с ним стали строиться люди, также переехавшие из близлежащих сел. Жители этой деревни для своих нужд использовали воду, протекавшую по Сазтамаку. Но через некоторое время она высохла и деревня осталась без воды. Поэтому население было вынуждено переселиться на берег Тулвы. Поселились на берегу , то место сейчас называется “Старый дом”. И здесь сельчан подстерегала неприятная неожиданность – Тулва размыла берег, приблизилась к деревне и стала ее подтоплять. Люди собрались и приняли решение поселиться вдоль берега реки Аклыш. Название этой реке дали по имени первопереселенца деда Аклыша. И деревня, где бы она не находилась, всегда называлась Аклуши. Сегодняшнее село вначале застраивалось в верхнем течении реки, затем стало разрастаться в нижнем течении по обеим сторонам реки.

*Историю Аклушей в 2013 году записала библиотекарь Аклушинской сельской библиотеки Илькаева Розалия Шархумовна.*

## “Алтын кәмә тавы”

Солтанай ягыннан, каенлыктан 1,5 км. юл үтүгә алда Сөҗән ягында бик матур “Алтын кәмә” тавы күренә. Бик күп еллар элек бу тау янында бер бабай яшәгән, аның алтын ишкәкле алтын көймәсе булган. Күлнең икенче ярында кешеләр яшәгән, ә бабай шул кешеләрне көймәсе белән бер ярдан икенче ярга ташыган. Көннәрдән бер көнне бу урынга яу белән килгәннәр. Бабай көймәсен таш белән тутырып күлгә батырган. Дошманнар көймәне алмасын өчен өстен калкан белән япкан, ә ишкәкне калкан өстенә куйган. Көймә күл төбендә, ә ишкәк урталыкта калган. Еллар үтүгә күл юкка чыккан, бары тик астан бик саф чиста су агып чыккан. Бу Сөҗән авылына кергәндәге чишмә дә инде. Ә тау “Алтын кәмә” тавы дип йөртелә башлаган.

*Масагутова Гөлҗихан сүзеннән китапханәче Назмукаева Миляуша язып алды. 2013ел.*

## “Гора золотая лодка”

Со стороны Султаная , после полуторакилометровой дороги по березняку, впереди перед деревней Сюзянь видно очень красивую гору, которая называется “Золотая лодка”. Много много лет назад возле этой горы жил дед, у него была “золотая лодка”. На противоположном берегу озера жили люди. Дед на своей золотой лодке перевозил их с одного берега озера на другой. В один из дней враги пришли сюда с набегом. Дед заполнил лодку камнями и затопил. Чтобы враги не добрались до лодки, он придавил ее щитом , а сверху положил весла. Лодка на дне озера , а весла посередине. С течением времени озеро исчезло, а на его месте появился родник с очень чистой водой. Это и есть родник , который находится при въезде в Сюзянь. А гора с того времени стала носить название – “Гора золотая лодка”.

*Со слов Масагутовой Гульзихан в 2013 году записала библиотекарь Султанаевской сельской библиотеки Назмукаева Миляуша.*

## “Алтын үрдәк”

Султанай авылының төньяк-көнчыгышында Тол елгасының уң як ярында биек “Кала” тавы урнашкан. Элек-электән тау агач –куакларның, үсемлекләрнең күплелеге белән тирә юньгә билгеле булган. Тауның иң биек башында тигез урында күл булган. Бу күл түп- тугәрәк һәм бик матур булган. Суында кошлар йөзеп йөрегән. Гатага (Мансуров) 18 яшь тулганда, ул Кала тауга күтәрелә, күл янына килеп баса. Күл уртасында ук бик матур үрдәк йөзеп йөри. Гата шул үрдәккә төзәп атып җибәрә.Үрдәк яр буена йөзеп килеп җитә дә алтын акчаларга әйләнеп ярга чәчелеп китә. Менә шуннан Гата баеп китә. Борынгы легендалар буенча, җиргә күмелгән алтын боланга, кошка әйләнеп йөри дигән сүз йөри, байлык бары тик тиешле кешесенә генә күчә икән. Күрәсен, бу байлык та Гатаны озак көтеп яткан һәм үрдәк булып күзенә күренгән һәм атып тидерүгә алтынга әйләнгән.

*Масагутова Гөлҗихан сүзеннән китапханәче Назмукаева Миляуша язып алды. 2013ел.*

## “Золотая утка”

На северо-западе от Султаная на правом берегу реки Тулвы располагается очень высокая гора (Кала тавы), возможно, она имела в свое время значение крепости, поэтому и была так названа. С давних времен гора славилась в округе богатством своей растительности. На самой ее вершине на ровном месте находилось озеро. Оно было совершенно круглым и очень красивым. На его водной глади плавали разные водоплавающие птицы. Когда Гате (Мансурову) исполнилось ровно 18 лет, он взобрался на гору и остановился на берегу озера. На самой середине озера плавала очень красивая

утка. Гата взял в руки ружье, прицелился и выстрелил прямо в утку. Раненая утка доплыла до берега и рассыпалась золотым дождем монет. С этого времени Гата и разбогател.

По древним поверьям, закопанное в землю золото превращается или в оленя или птицу и достается только определенным людям. Видимо, богатство долго дожидалось Гаты Мансурова и в виде утки попалось ему на глаза. А после его выстрела утка превратилась в золото.

*Со слов Масагутовой Гульзихан в 2013 году записала библиотекарь Султанаевской сельской библиотеки Назмукаева Миляуша.*

## Байавыл турында легенда

*Мин Байавыл кешесе. Монда минем балачагым, яшьлегем, картлыгым – монда минем кендек каным тамган. Монда минем ата-бабаларым сукмагы, шул сукмаклардан мин дә үтәм. Авылым – Байавылым, мин синең кочагыңда үскән кеше.*

*Минем авылым бик матур урынга урнашкан. Авылымның Әмҗе елгасы гына ни тора! Ахун тавы, Бәкин башы, Кала тавы, Айбатбуй буе... Табигате дә, кешеләре дә гүзәл, искиткеч ягымлы... Барлык урыннары да үткән тарих белән бәйле. Ачык таудагы каберне генә әйтик. Без кечерәк чакта бу каберда сугышчы күмелгән диләр иде, төнлә каберда ут күренә дип куркыталар иде.Соңрак төшендек, кабердән фосфор күтәрелә, шул төнлә ут булып күренә икән, ә без юләр балалар шуннан узарга курка идек.*

*Авылым турында өлкәннәр шундый легендалар сөйлиләр иде. Латифә, Майбәдәр әбиләрдән ишеткәнем бар иде, аларны куып урманга йөри идек.*

Безнең авыл урнашкан урында бер бабай килеп, гаиләсе белән көн күрә башлаган. Килеп урнашу белән агач умарталар торгызып, бал кортлары үрчетеп җибәргән. Борынгы заманда кешеләр җәяү йөргәннәр. Авылдан – авылга йөреп туенучылар да күп булган. Мәкәрҗәгә**,** Пермьгә,Осага чана сөйрәп сатуга йөргәннәр. Кортчы бабайның йорты Катерина юл буенда ук (хәзерге Промарт урында) булган. Хәлләре беткән юлчылар бабайга кереп ял итә торган булганнар. Бабай аларга ипигә бал сылап чәй эчереп чыгарган.

Бабай янында урнашып башка кешеләр дә яшәп киткәннәр. Юлчылар бу урында бай кунакчыл кешеләр яшиләр дип хәбәр таратканнар. "Бай килде" дигән хәбәр бик тиз тарала, шуннан аны Байгилде дип йөртә башлыйлар. Ә авылыбызга Байавыл исеме бирелә.

*Байгилде бабайның юмартлыгы, кунакчыл булуы авылым кешеләренә ул хәзер дә үрнәк. Авылыбыз халкы арткаman – арта бара, җирләре зурая: Олата башлар, Бәкин башлар, Миңгер башлар. Байавылда яшәүчеләрнең бу җирләре зур һәм уңдырышлы булган. "Җире барның – ашы бар!"- ди халык.*

*Бу легендада дөреслек бар. Байавыл исеме җисеменә туры килә. Җирләре дә бай, халкы да бай. Элегрәк безнең очта гына да: Зәйнәгетдин, Нурислам,Нигаметҗан,Госман,Рәхим,Шәрип бабайлар кортлар карадылар. Минемчә, бу эш белән шөгыльләнү тамырлары авылым турындагы легенда тарихлары белән тоташа.*

Мансурова Халимә Лотфулла кызы сүзеннән Байавыл китапхәнәчесе Уразова Айгюль Гаптелмәҗит кызы язып алды. 2013 ел.

**Легенда о Куземьярове**

*Я жительница Куземьярово – здесь прошли мое детство, молодость, старость - здесь моя «пуповина». Здесь тропинки, протоптанные моими предками, по этим тропкам ходила и я. Мое любимое село, в твоих объятиях я выросла.*

*Мое село расположено в очень красивом месте. Чего стоят наши река Амзя, горы Ахун, Бакин баш, Кала тау, Айбатбуй. Прекрасная ласковая природа и замечательные люди. Любое место здесь связано с историей. Например, могила на горе Ачык тау . Когда мы были маленькими, говорили, что в этой могиле похоронен солдат, пугали ,что ночью эта могила светится. Позднее поняли, от могилы исходит фосфор, ночью он светится. А мы, глупые дети, боялись ходить мимо этого места.*

*О селе пожилые люди рассказывали легенды. Я слышала их от бабушек Латифы и Майбадар, с которыми мы вместе ходили в лес.*

На место, где сейчас расположено село, пришел дед и стал жить вместе со своей семьей. Сразу после обустройства соорудил деревянные ульи и начал разводить пчел. В давние времена люди все больше передвигались пешком. Немало было и нищих, которые кормились тем, что ходили от деревни к деревне. Пешим ходом, таща сани, ходили торговать на ярмарку в Нижний Новгород, Осу, Пермь. Дом пасечника находился рядом с екатерининской дорогой (сейчас это место называется Промарт ). Чтобы отдохнуть, путники заходили к деду. Он угощал их чаем и хлебом, сдобренным медом.

Обосновавшиеся возле пасечника люди тоже прижились. Путники рассказывали о том, что здесь живут богатые, гостеприимные люди. Весть о том, что прибыл «Богач» разлетелась быстро. И стали звать этого деда Байгильде (Бай килде). А селу дали название Байавыл – богатое село.

*Щедрость,гостеприимство Байгильде бабая и сегодня пример для сельчан.Сельское население все прибывает и прибывает, растут и размеры земельных наделов- Олата баш,Бакин баш,Мингер баш. Эти земли куземьяровцев были большими и урожайными. И народная поговорка гласит: “Есть земля – есть еда”.*

*В этой легенде есть подлинность. Название “Богатое село” соответствует действительности: и земли богатые и люди богатые. Раньше только рядом с нами занимались пчеловодством Зайнагетдин, Нурислам, Нигаметжан,Гусман,Рахим, Шарип бабай. На мой взгляд, корни этого занятия напрямую связаны с легендой о моем селе.*

Со слов Мансуровой Халимы Лотфулловны записала библиотекарь Куземьяровской сельской библиотеки Уразова Айгюль Гаптелмазитовна (2013 г.)

**“Җиде газизләр**”

Җиде газизләр дип безнең районыбызның ин биек таулары әйтелә. Бик күп еллар элек бер-бер артлы, бер туган җиде балалар дөньяга килә. Алар берсенән – берсе лачын шикелле көчле, җигәрле, таза балалар булып үсәләр. Бу егетләрнең җиде бөртек булулары җиде биек тау санына да туры килгән. Безнең бабаларыбыз яшәгән урында җиде биек таулар урнашкан булган. Бу тауларның башына менсәң бик еракны җирләр күренгән булган, җирне басып алып килеп керергә теләгән дошманнар да монан бик яхшы күренәрләр дип уйлаган халык һәм үзләренең туган якларын, туган җирләрен яраткан җиде газиз туганнарны халык тынычлыгын саклаучылар итеп шул тауларга озатканнар. Алар бер үзләре шул тауларда яшәргә риза булганнар, ир егетләр үзләренең туган

җирләрен, халкын яратканнар, тынычлык өчен үзләренең тормышларын да бирергә әзер булганнар.

Бу таулар шар формасында урнашкан булган һәм бер-берсенә күренеп торганнар. Дошман һөҗүм итсә ут ягып бер берсенә дә, халыкка да хәбәр иткәннәр. Шулай җиде бер туган, җиде газизләр бабаларыбызның тынычлыгын саклаганнар. Шуңа күрә дә инде тауларны хәзер дә олы яшьтәге апа- абыйларыбыз җиде газизләр дип йөртәләр.

Кызганычка каршы инде кайбер авылдагы тауларның исемнәре хәзер үзгәртелгән. Бу вакытларда алар болай дип аталганнар:

Тол баш авылында –“ Солтан Әхмәт” тау

Башап авылында –“ Оек” тау

Султанайда – “Солтангази” тау

Әрҗән авылында – “Хәсән Шәех” тау

Ермия авылында “Марат хаҗи” тау

Сарашта – “Минлемәгәсум” тау, хәзерге вакытта бу тау “Кала тау” дип атала.

Оса ягында (ул Кама елгасы астында калган)- “Сәетсәлим” тау.

*Сараш авылында яшәүче Масагутова Мөнибә апа сүзләреннән язып алды(2013ел.) Тимганова Кадрия Ясавий кызы.*

## “Семь святых”

В нашем районе семью святыми называют семь самых высоких гор.Много лет назад один за другим появились на свет семь родных братьев. Они как соколы росли сильными, ловкими, здоровыми. Число братьев соответствовало количеству семи высоких гор, которые расположились на нашей земле. Если взобраться на их вершины,было видно очень далеко. Люди подумали, что с них можно будет вовремя заметить врагов, которые придут на нашу землю. И отправили семь молодых соколов на семь вершин,чтобы охраняли они любимую землю и спокойствие народа от ворогов. Братья согласились в одиночестве жить на этих вершинах и посвятить свою жизнь служению родной земле и родному народу.

Эти горы были расположены в форме шара и с каждой горы было видно другую. Если приближался враг, братья разжигали на вершине огонь и сообщали весть друг другу и людям. Так семеро братьев сохраняли покой наших предков. Поэтому и сегодня пожилые называют эти семь гор “семь святых”.

К сожалению, сегодня названия некоторых гор изменилось. В давние времена они назывались так: В деревне Тулбаш –“ Солтан Ахмат” тау

В Ашапе –“ Оек” тау

В Султанае– “Солтангази” тау

В Краснояре– “Хасан Шаех” тау

В Ермии - “Марат хаҗи” тау

В Сарашах– “Минлемагасум” тау, сейчас эта гора называется “Кала тау” .

В стороне Осы (она осталась под Камой)- “Саетсалим” тау.

*Записано библиотекарем Сарашевской библиотеки Тимгановой Кадрией Ясавиевной со слов Масагутовой Мунибы, жительницы Сарашей. 2013 г.*

## История Бичуринского поселения в названиях

**Урочище «Заит жир» -** Рядом с селом Бичурино по дороге в д. Учкул левая низина с северной стороны горы Гыйззат называется «Заит җир». До октябрьской революции эти места принадлежали Загиту Камакаеву. Он пахал, сеял злаковые культуры и этим жил. В селе Бичурино жили его сыновья Сафий, Гарап, Гатаулла.

*Записано со слов Ветерана ВОВ Камакаева Назия Гатаулловича, 25.09.1927 г.р. – 29 августа 2013 года.*

**«Куян бабай тау -** По дороге в деревню Бардабаш после реки Баршинда по обе стороны дороги открывается поле с возвышенностью. В годы коллективизации рядом с этой возвышенностью на левой стороне была построена кроличья ферма, принадлежавшая колхозу. Ухаживал за кроликами Иткинов Гарифел. *Отец Иткинова Хамзы, заслуженного штурмана СССР, ветерана ВОВ.* Он жил при ферме с семьей. Дети из Бичурино приходили играть с его детьми и с кроликами. К охраннику Гарифелу обращались «куян бабай».

**I Бардабаш и II Бардабашка -** На запад в пяти и восьми километрах от села Бичурино есть две деревни Первый Бардабаш и Вторая Бардабашка. Откуда появилась нумерация этих деревень? При руководстве колхозом им. Нариманова Якшиевым Салихом, в 1976 году колхоз «Ленинец» Куединского района присоединили к Бичуринскому сельскому совету, куда входили деревни Бардабашка и Марамья. В 1983 году Марамья прекратила свое существование, а в составе сельсовета уже была деревня Бардабаш. Чтобы не путать эти деревни в отчетах колхоза их разделили на две бригады и стали именовать Первый Бардабаш (без приставки «ка») и Вторая Бардабашка. Местное население до сих пор называют Вторую Бардабашку «Урыс Бардабаш», что означает «Русская Бардабашка».

- *Записано со слов бывшего начальника участка д. Первый Бардабаш Амировой Фарзии Шамгуловны, 15.06.1952 г.р. – 20 июня 2013 года.*

**Каенавыл чишмәләре**

***Чириз елгасына агып төшкән чишмәләр авылдан барганда сул яктан.***

**Токмык чишмә** - бик кыска булганга шулай атала

**Чабу чишмәсе** – кешеләрнең чабулыклары булган җирдән ага.

**Карагай чишмәсе** – карагай агачы күп үскән җирдән ага.

**Кузайкуш** – кеше исеме. Иван Грозный вакытларында крещениядән качып килгән башкорт. Аның җиреннән аккан чишмә.

**Завод чишмәсе** – 20 че гасырларның 60нчы елларында мунчала заводы булган. Мунчала төшергәннәр һәм эшкәрткәннәр.

**Усаклы чишмә-** усак күп үскән җирдән ага.

**Чириз баш** – елганың башы, 20 гасырның 40-50 елларында Чириз авылы булган, хәзерге вакытта беткән. Чириз исеме урыс сүзе Чирездан килеп чыккандыр ахры дип уйланыла. Чөнки Иске Чат авылы янында урыс авылы булган. Шул кешеләр чыгарган исем дип уйланыла.

***Чириз елгасының уң як чишмәләре***

**Еван чишмәсе** – бәлки Иван, бәлки елан сүзеннән килеп чыккандыр.

**Челтерәмә чишмә -** таудан челтерәп ага.

**Урта чишмә -** таудан ярып чыга, тыныч ага, алты чишмә уртасында урнашкан.

**Мәкәли чишмә -** кеше исеме. Мәкәли дигән диванарак яшь егетне качкыннар үтереп күмгән җирдән ага.

**Кантуган чишмә -** кеше исеме. Башкортның җиреннән аккан чишмә.

**Бигәнби чишмә-** кеше исеме, авыл читендә урнашкан. Иң тәмле сулы чишмә. Авыл халкы шул чишмәдән су ала.

**Күперле чишмә-** авыл эчендә, күпере бар.

**Әтәч чишмә-** әтәч күмгәннәр ди, шуннан чишмә бәреп чыккан.

## Маяк тау

Каенавыл тирәсендәге иң биек тау. 20гасырда гражданнар сугышы вакытында анда пост булган. Иң биек агачка менеп тирә-юньне карап торганнар, чөнки аннан бик ерак җирләр күренгән, аклар килсә дә, кызыллар килсә дә, авыл халкына хәбәр җиткергәннәр.

## Саксар тау

Һәм инде авыл халкы качып, безне тау саклар әле, дип тауга киткәннәр. Саклар тау Саксарга әйләнгән тора-бара. Авылдан аклар яки кызыллар чыгып киткәнче, кешеләр азык-төлек, су алып шул тауда яшеренеп торганнар. Берзаман таудагыларның сулары беткән, авылга су алырга Хөсәен исемле 16 яшьлек егетне җибәргәннәр. Су алып кире китеп барганда акларның дозоры егетне күреп атып үтерә. Авылдашлары аклар авылдан киткәч, аны шул үтергән җиргә күмәләр. Хөсәен шаһит каберлеге хәзер дә саклана.

*81 яшьлек Сакаева Әнүзә Исмакҗан кызы сүзләреннән Мустаева Люра язып алды. Каенавыл, 2013 ел, май.*

## Березниковские ручьи

### *Левобережные притоки реки Чириз*

**Ручей Токмык-** называется так потому, что очень короткий.

**Чабу чишмәсе -** течет по покосам.

**Карагай чишмәсе-** течет по сосновому лесу

**Кузайкуш** – имя человека, башкира, который во времена Ивана Грозного скрылся от насильственного крещения. Ручей протекает по его земле.

**Завод чишмәсе-** в 60-х годах 20 века здесь был завод по производству мочала. Здесь его мочили и выделывали.

**Усаклы чишмә-** течет по месту, где много осины.

**Чириз баш-** исток реки Чириз. В 40-50 годах двадцатого века была деревня Чириз, сейчас она исчезла. Думается, что название реки произошло от русского названия деревни, которая находилась недалекого от деревни Старый Чат.

### *Правобережные притоки реки Чириз.*

**Еван чишмәсе** – произошло или от русского имени Иван, или от татарского слова елан-змея.

**Челтәремә чишмә -** течет с горы с журчанием.

**Урта чишмә -** Протекает по середине горы,течет спокойно, находится между шестью ручьями.
**Мәкәли чишмә -** мужское имя. Течет по месту, где злодеи убили и схоронили слабоумного юношу по имени Макали.
**Кантуган чишмә -** мужское имя, течет по земле башкира по имени Кантуган.
**Бигәнби чишмә-** Биганби имя, течет по окраине села.Ручей с самой вкусной водой,сельчане берут оттуда воду.
**Күперле чишмә-** находится в середине села, через ручей сооружен мост.
**Әтәч чишмә-** здесь похоронили петуха и из этого места появился ручей.

**Маяк тау**

Самая высокая гора возле села Березники. В двадцатом веке во время гражданской войны там выставляли пост. Забирались на самое высокое дерево и наблюдали за окрестностями, так как оттуда была видно далеко вокруг. Сообщали сельчанам и о приближении белых, и о приближении красных.

**Саксар тау**

На этой горе сельчане хоронились от неприятеля, считая, что гора их защитит. Постепенно саклар (сохранит) превратилось в саксар. Пока из деревни не выйдут или белые или красные сельчане пережидали на этой горе, взяв с собой еду и воду. Как то раз, когда закончилась вода для питья, селяне отправили за водой 16-летнего юношу по имени Хасан. Когда он возвращался с водой назад, белый дозор увидел юношу и застрелил. После того, когда белые ушли из села, односельчане похоронили юношу на том месте, где он был убит. До сих пор сохраняется захоронение Хасана, убитого за народ во время войны.

*Со слов 81 летней Сакаевой Анузы Исмакзяновны записала березниковский библиотекарь Мустаева Люра. Май 2013 г.*

**Легенда о Лешачьей горе**

Недалеко от деревни Шермеинск расположен холм, который носит название «Лешачья гора». По преданиям местных жителей, здесь живет сам Леший, хозяин горы и леса. Он в свои владения никого не пускает, а если вдруг кто-нибудь забредет туда, то Леший начинает «водить», то есть кружить по одному и тому же месту. И может случиться так, что обратно дорогу к дому ты не найдешь, если только не вспомнишь, что надо задобрить хозяина. Для этого, если есть с собой еда, надо положить ее на пенек и предложить отобедать. Ну а если еды с собой нет, то тут необходимо вспомнить, что можно перевернуть наизнанку свою одежду. Только тогда можно выбраться из этого места.

По рассказам Оленевой Анны Андреевны (ныне покойной), как-то там заблудился охотник. Долго плутал, слышал собачий лай, видел огоньки, а выйти из леса не мог, пока не сообразил, что водит его Леший. А дело было уже к ночи. Так он говорит, что как только перевернул шапку и куртку, оказался прямо на дороге. Бежал, а ему все казалось, что за ним кто-то пристально наблюдает.

Со слов Шиловой Надежды: « Таких случаев было очень много. Поэтому всех приезжих и детей предупреждали, чтобы они ягоды собирали только под Лешачьей горой, а на гору не ногой, а то можешь не вернуться».

*Со слов старожилов записала библиотекарь Шермейской сельской библиотеки Ольга Модестовна Волкова. 2013 г.*

**“Мир болын кысык”**

Сәфәр бәгырь чишмәсен бераз үтеп “Мир болын кысык”ка килеп чыгасың. Бусы да борылышлы, кысык җир.

Султанай һәм Никольск авыллары чиге дә биредә урнашкан. Чик буе булганга да ике авыл кешеләре чабу, җир мәсьәләсен тыныч юл белән хәл итәр өчен менә шул ачыклыкка җыелганнар. Менә шуңа да бу аланлык “Мир болын кысык” дип йөретелгән.

*Масагутова Гөлҗихан сүзеннән Султанай китапханәчесе Назмукаева Миляуша язып алды. 2013 ел.*

**“Мировая поляна”**

Пройдя мимо родника Сафара-багыря , скоро попадешь на “Мировую поляну”. Это выгнутое, узкое место.

Здесь также расположена граница между султанаевскими и никольскими землями. Так как поляна находилась на границе, жители двух сел собирались здесь и миром решали на ней земельные вопросы и проблемы с покосами. Поэтому это место и называется “Мировая поляна”.

*Со слов Масагутовой Гульзихан в 2013 году записала библиотекарь Султанаевской сельской библиотеки Назмукаева Миляуша*

**«Сәфәр – бәгырь”**

Олы юл Куеда ягына таба бара. Сул якта биек таулар, уң якта сазлык, тигез урыннар күзгә ташлана. Иң кискән борылышлы урында Сәфәр –бәгырь чишмәсе агып ята. Кайчандыр бу урынга Сәфәр исемле кеше килеп урнаша. Ул биредә чишмәне буып буа да ясый. Бу урын бик тынгысыз, начар урын (аномальная зона) була. Ул урында бик еш авариялар (улем белән) булып тора. Элек шул урында чабулыклар да күп иде. Әкрен-әкрен аларны чапмас булдылар. Кем чаба, шуларга нәрсәдер була, я малы, я үзе авырый. Әнә шундый хикмәтле урын ул.

*Масагутова Гөлҗихан сүзеннән Султанай китапхәнәчесе Назмукаева Миляуша язып алды. 2013 ел.*

## «Сафар»

Главная дорога ведет в сторону Куеды. Слева – высокие горы, справа- болото, в глаза бросается ровная местность. На самом крутом повороте дороги вытекает ручей , прозванный Сафар багыйрь.

Когда-то на этом месте обосновался человек по имени Сафар. Он перегородил ручей и сделал запруду. Это место оказалось очень неспокойным, плохим (аномальная зона).Здесь часто случаются аварии со смертельным исходом. Раньше было много покосов. Постепенно их забросили. Так как с косившими что-либо случалось: заболевал или косарь или его скот. Такое это злосчастное место.

*Со слов Масагутовой Гульзихан в 2013 году записала библиотекарь Султанаевской сельской библиотеки Назмукаева Миляуша.*

## Султанай алыплары

Султанайның төньяк-көнчыгышында тау тезмәләре тезелеп китә. Тау буенда зур урман үсә. Урманлык гөмбәгә, җиләк -җимешкә бик бай. Сөҗән юлыннан урман буйлап бара торгач, кинәт ачыклык пәйдә була. Бусы каен ара дип атала. Бу урында агач та үсми. Менә шул урында кайчандыр алыплар яшәгәннәр. Алар бик озын буйлы булган. Ишек алдына кергәндә читәнне атлап кына кергәннәр. Алар ни өчендер барысы да кисәк үлгәннәр. Өчесен Султанай белән Башап түз арасында 3 каен төбенә күмгәннәр. Хәзер дә ул каеннар исән. Кырыеннан үткәндә әллә нинди шомлы тавышлар килә. Кешеләр аннан үткәндә, аеруча кичләрен, бик куркып кына йөриләр.

*Масагутова Гөлҗихан сүзеннән Султанай китапхәнәчесе Назмукаева Миляуша язып алды. 2013 ел.*

## Султанаевские великаны

На северо-западе Султаная простирается горная цепь. На горах растет густой лес. Лес очень богат грибами и ягодами. Проезжая вдоль леса по сюзянской дороге, неожиданно встречаешь открытое место. Оно называется березовое место. Здесь деревья и не растут.

Тут когда-то жили великаны. Они были очень высокие. Заходили во двор, перешагивая изгородь. Почему-то они все внезапно умерли.

Трое были похоронены между Султанаем и Усть-Ашапом под тремя березами. Эти березы и сейчас стоят. Когда проходишь мимо, слышатся какие-то зловещие звуки. Прохожие ,особенно вечерами, ходят мимо с большой опаской.

*Со слов Масагутовой Гульзихан в 2013 году записала библиотекарь Султанаевской сельской библиотеки Назмукаева Миляуша.*

## “Тәкә тау”

Тәкә тау. Бу тауның исеме турында укыгач та сез көлерсез. Көлке түгел. Элек без Сарапул өязенә кергәнбез, “Җиде газизләр” булган. Газизләрнең берсе Тауавылдан ерак түгел Ыек тауда сакта торган. Биек Толтыр тау ярында. Бу Әрәмавылга якын урын була инде. Элеккеләр Урал таулары итәкләре дип йөрмәгәннәр, Толтыр тау дигәннәр.

Байавылда Могалифә кул арасы янында текәрәк кенә таучык бар. Бу таучыктан Кодаш, Үдик, Каенавыл яклары һәм авылыбыз да яхшы күренеп тора. Менә шул Ыек таудан хәбәр бирүченең уты-сигналы күренә торган булган. Авылдан шушы таучыкка менеп карап куркыныч янавы турында белгәннәр. Бу таучыкны авыл халкы изге урын итеп йөрткән. Өязне саклаучы “Җиде газизләр” тора бара үлеп беткәннәр, соңрак авыл кешеләре алар үлеменә багышлап шул тауда тәкәләр суйганнар, шуннан бу тау “Тәкә тау” исемен йөретә башлый. “Җиде газизләр” исеме дә изгеләштерелгән, аларга атап хәер бирсәң эшләрең уңышлы була.

*Ә без оч җыен балалары бу тауга менеп уйный идек: “Сукыр тәкә”, “Тәкә,тәкә, тәкушкә”. Бер кеше “әби” итеп сайлап куела. Аннан бер бала арты белән борылып баса, ә калганнар куак араларына, кырмыска оя артларына качалар. Арты белән торган бала әбидән килеп сорый:*

*-Тәкә,тәкә, тәкушкә*
*Тәкә кергән мөгешкә*
*Курмәдеңме, бабушка?*

*Әби:*

*-Күрмәдем , балам, күрмәдем,-ди.*

*Шуннан эзләү башлана иде. Әле мин шуны хәтерлим: Тәкә тауда учак ягып колхозчыларны ашаталар иде, аннан әниләр яулык очларына калаклап он салып кайталар иде.*

*“Җиде газизләр” турында безгә Асия әби сейләде. Ул искене күп белә иде, хәзер мәрхум инде, безнең дә чәчләргә чал керде. Тормыш давам итә. Заманалар үзгәрә тора. Үткәннәр тарихта истәлек булып калсын иде.*

Мансурова Хәлимә Лотфулла кызы сүзеннән Байавыл китапханәчесе Уразова Айгюль Гаптелмәҗит кызы язып алды. 2013 ел.

## “Баранья гора”

Услышав название горы, вы, наверное, рассмеётесь. Но ничего смешного. Когда-то мы входили в Сарапульский уезд. В нашей местности было семь газизов. Один из газизов стоял на посту недалеко от Усть-Тунтора на горе Ыек, возле круч высокого Толтыра. Это место недалеко от деревни Конюково. Старики не называли горы Уральской грядой, а звали горы Толтыр тау.

В Куземьярове недалеко от межгорья Могалифы есть небольшая крутая горка. С нее хорошо просматриваются села Кудаш, Елпачиха, Березники и наша деревня. Вот с этой горы Ыек хорошо были видны сигнальные огни. Сельчане, взобравшись на эту гору , узнавали, не угрожает ли им опасность. Эту гору сельчане считали святым местом.

Охранники уезда семь газизов постепенно умерли. Позже селяне в их память на горе забивали скот, после этого гора стала носить названия Баранья гора. А семерых

газизов стали считать святыми. Считается, если в их память даешь подаяние, то дела твои удадутся.

*А мы, местная ребятня, забирались на гору и играли в игры “Слепой баран”, “Баран,баран,барашек”. Один из нас выбирался “бабушкой”. Другой поворачивался спиной, а остальные прятались в кустах, за муравейником. Ребенок, стоящий спиной, спрашивал у “бабушки”:*

*Баран,баран,барашек*
*Баран забился в угол*
*Не видела ли бабушка?*

*“Бабушка” отвечала:*

*-Не видела , детка, не видела.*

*Потом начинались поиски спрятавшихся. А еще я помню, как на горе разжигали костер и кормили колхозников. А потом мамы, положив ложками муку в угол платка, возвращались домой.*

*О семи газизах нам рассказывала бабушка Асия, она много знала о старине,сейчас она уже умерла. И мы поседели, жизнь продллжается. Времена меняются, но хочется ,чтобы прошедшее осталось в памяти сельчан.*

Со слов Мансуровой Халимы Лотфулловны записала библиотекарь Куземьяровской сельской библиотеки Уразова Айгюль Гаптелмазитовна (2013 г.)

**Түбән авыл**

**Черки буам**.(Комаринная запруда) Зимасова Ләбибә Шамил кызының карт әтисе буам буып мунчала төшереп яткан, кушаматлары “черки” булганга “черки буам” дип атап куйганнар.

**“Чияле тау”-** чия куаклары бик күп булган өчен.

**“Пумиллик”-** Түбән авылга төшкән вакытта сул якта зур гына агачлык кала. Элек җирле телдә чыршы агачының яшьләвеген “пумиллек” дип атап йөркәннәр, бу шуннан калган да инде.

**“Чүрәле тау”-** Элек заман безнең авыл аша китеп, Тол елгасын кичеп шушы тау аша Кунгурга йөргәннәр. Җирле халык телендә “чүрә юньнән” бөтен кеше шуннан йөргәнгә элегрәк ул тауны “чүрә юл” дип атап йөрткәннәр.

**“Баткак ара”-** Һәрвакыт баткак (пычрак) булган өчен.

**“Мокаш тау”-** Шарифулла абыйның әтисе Миннехуҗа исемле булган, аның хатыны Магъшука исемле,аны кыскартып Могаш дип атап йөрткәннәр. Могаш әби Толны телеп чыгып агач көрәк белән генә җир эшкәртеп бәрәңге утырта икән. Бу бәрәңгене шәңгәсе тәмле була дип, шәңгә пешерергә генә токкан. Бу тауны Мокаш тау дип атап куйганнар. (безнең авылда Мәгъшука әбинең Нәҗмегариф исемле малае белән хатыны яши).

**“Каравыл тау”-** Зимасова Ләбибә Шамил кызының карт әтисе җир эшкәртеп иген чәчкән. Урак вакыты җиткәч, игенен урлый күрмәсеннәр дип, караулап ята торган булган, шуңа да инде “Каравыл тау” дип атап куйганнар.

“**Арыслан кызлары җире**”- Арыслан исемле кешенең ике кызы булган. Аклар һәм кызыллар заманында, аклар бу кызларны үтергәннәр. Шуңа “арыслан кызлары җире ” дип атап куйганнар.

**“Тугызак тау”-** Илькаев Риза Гаял улы сүзләреннән : Кызыллар Кодаш авылы ягыннан килеп Чуккаеннан таудагы акларга атып ятканнар. Аклар качып киткән вакытында үзләренең үлгән тугыз сугышчан дусларын ташлап киткәннәр. Аклар кайда үлгән, шунда күмелгән, шуңа да инде тауны “тугызак” дип атап куйганнар.

*Маматова Тәрҗемә Гафи кызы сүзләреннән Юлаева Фәнисә Хәмис кызы язып алды (2013 ел.)*

## д. Ишимово

**Черки буам**.- Комаринная запруда. Дед Зимасовой Лябибы Шамиловны занимался заготовкой мочала, а его прозвище было “комар” , поэтому и назвали эту запруду комариной.

**“Чияле тау**”- Вишневая гора. Назвали потому, что на ней росло много вишневых кустов.

**“Пумиллик”-** Когда приближаешься к Ишимово, слева остается довольно большая роща. Раньше на местном диалекте еловый подрос называли “пумиллек”, от этого и пошло ее название.

**“Чүрәле тау”- Ближняя гора (местн.)** В давние времена через наше село ездили до Кунгура. Проезжающие пересекали Тулву и эту гору. На местном диалекте “чүрә юньнән” (поблизости). Так как все ездили по этой дороге, раньше эту гору называли “Ближняя дорога”.

**“Баткак ара”-** Обозначает не просыхающее, всегда грязное место.

**“Мокаш тау”-** Отца Шарифуллы абзыя звали Миннехужа, его жена Магашука. Сокращенно - Могаш. Бабушка Могаш, перебравшись через Тулву, обрабатывала деревянной лопатой землю и сажала картошку. Эту картошку использовали только для выпечки шанег, так как считали, что они получаются очень вкусными. Поэтому гору и назвали по имени бабушки Мокаш. ( *Сейчас в селе проживает сын Магашуки Назмегариф с женой).*

**“Каравыл тау”-** Дед Зимасовой Лябибы Шамиловны обрабатывал землю и сеял хлеб. Когда наступало время жатвы, он караулил свой урожай, чтобы его не украли. Поэтому так и назвали гору .

“**Арыслан кызлары җире**”- У человека по имени Арыслан было две дочери. Во время гражданской войны белые убили этих девушек. Поэтому и назвали это место – земля дочерей Арыслана.

**“Тугызак тау** . Со слов Илькаева Ризы Гаяловича, красные, прибывшие со стороны Кудаша, обстреляли белых, которые находились на горе. После отступления белые оставили мертвыми девятерых своих солдат. Где они погибли, там и похоронены. Поэтому гору и назвали “Девять белых”.

*Со слов Маматовой Тарзимы Гафиевны записала ишимовский сельский библиотекарь Юлаева Фаниса Хамисовна. 2013 г.*

## «Түмәлчек тау»

Безнең әрәмәлектә, елга буенда бер таучы бар. Аны Түмәлчек тавы дип әйтәләр. Без шул тау итәгендә уйнап үстек. Бу урын, бу тау турында күп, бик күп элек булган хәлләр турында истәлекләр сакланган. Без вак чакта әби-бабайлар безне кисәтәләр иде:

- Ул тауда уйнамаң, җиләген ашамаң, кулыгыз корыр, аягыгыз черер!- диләр иде.

Без бу тауның изге урын икәнлеген үсә төшкәч кенә аңладык...

Күп еллар элек каты ачлык башланган. Ашарга булмаган, кешеләр ачлыктан кырылганнар гына, күпләре ачлыктан шешенеп үлгәннәр. Бу котычкыч еллар булган. Менә шул елларда була бу хәл: ике үсмер кыз бала күрше авыллардан хәер сорашып, хәлләре бетеп кайтып килгәндә шунда егылалар. Су эчеп алырга дип елгага төшәләр, ләкин алар су эчкәнгәме, ачлыктанмы – шунда ятып үлгәннәр. Авыл кешеләре кызларның үле гәүдәләрен соң гына күрәләр: кортлап, чери башлаганнар икән. Авылымның хәллерәк кешеләре барып аларны шунда гына күмгәннәр.

Без үскәндә бу кабер тау сыман булып, кечкенә таулар булып икегә аерылып тора иде. Каберләре югалмасын дигәндәй бу урын тора бара текәләнеп, күтәрелеп киткәндәй булды. Шушы ике кыз күмелгән урынны Түмәлчек тау дип йөртәләр дә инде.

Хәзерге көндә язгы ташу вакытында бу урын ашалып,җимерелеп бара, шулай булса да, истәлекләр саклана, кызык хәлләр күзәтелә бу урында...

Гайнур әби кичкырын керләр чайкарга елгага төшкән. Чайкый торгач, Түмәлчек тавы ягына караса, Әмҗе елгасы буенда актан киенгән ике кыз бала җиз комганнар чистартып утыралар ди. Әби озак кына карап торгач, юкка чыгалар болар. Кайтып җиткәч Гайнур әби бу хәлне баларына сөйли.

Авылыбызның сабантуйлары да шушы урыннан ерак түгел урында үтә иде. Бервакыт шулай Мухамаматулла абый сабантуе көнне эчеп, кайта алмыйча шул Түмәлчек тавында йоклап кала. Кичке вакыт җиткәч:

-Кулларым, аякларым авырта, безгә авыр!- дигән тавышка уянып китә бу. Ни күзе күрсен, янында актан киенгән ике кечкенә кыз балалар басып торалар.

-Өеңә кайтып йокла,- диләр.

Абый,өнемме-тешемме бу, диеп аенып кайтып китә.

Соңрак бу абый әллә зиярат тотты ( сарайда эшли иде), әллә Түмәлчек тау тотты мы, кагылды дип, саташып, акылдан шашып үлде.

Түмәлчек тавы – ачлыктан үлгән кызларның мәңгелек истәлеге. Ул безгә ачлык елларының коточкыч булуы турында кисәтеп тора.

*Мансурова Хәлима Лотфулла кызы сүзеннән Байавыл кикапхәнәчесе Уразова Айгюль Гаптелмәҗит кызы язып алды (2013 ел.)*

**“Круглая гора”**

Вдоль реки возле кустарников есть небольшая круглая горка, ее так и называют Круглая гора. Мы в детстве играли у ее подножья. Об этом месте, об этой горе сохранилось очень много старинных историй. В детстве дудушки и бабушки предупреждали: “Не играйте на этой горе, не собирайте ягоды. Иначе отсохнут руки, сгниют ноги.” Мы поняли,что это святое место только, когда повзрослели.

Много лет назад случился страшный голод. Есть было нечего, люди умирали, опухали от голода. Это были страшные годы. В это время и произошло это несчастье. Две девочки подросткового возраста, воззвращались домой, они ходили по соседним деревням собирать милостыню. Обессилев остановились здесь, чтобы попить воды. То ли от того, что попили, то ли от голода упали на месте и умерли.Сельчане нашли трупы поздно, они уже начали разлагаться. Те у кого еще остались силы, похоронили девочек на том же месте, где они и умерли.

Когда мы были маленькими, эта могила выглядела как две небольшие горки. Со временем это место стало выше, круче , как будто кто-то хотел, чтобы эти могилы не потерялись, не забылись. Место, где похоронены эти девочки, и называют Тумалчак тау.

Сейчас во время половодья оно размывается, но несмотря на это память сохраняется, и здесь происходят загадочные события.

Как –то бабушка Гайнур вечерком пришла на речку прополоскать белье. Прополоскав белье, бросила взгляд на Тумалчак тау и видит, возле речки Амзи две девочки подростка в белых одеждах чистят серебряный кумган. Смотрела она довольно долго, затем они исчезли. Вернувшись домой бабушка рассказала о виденном своим детям.

А вот еще случай. Сельский сабантуй также проходит недалеко от этого места. Как-то раз Мухаматулла абый, много выпив на празднике, заснул на этой горке. Под вечер проснулся от голоса:

- Нам тяжело, болят руки и ноги.

И видит – рядом стоят две маленькие девочки, одетые в белые одежды.

-Иди домой и спи там,- говорят они.

Мужчина от испуга , не поняв: то ли это сон , то ли явь, протрезвел и кинулся домой.

Позже, то ли на него повлияло захоронение, то ли гора Тумалчек, но он сошел с ума и умер.

Гора Тумалчек – это память об умерших от голода девочках, она вечно напоминает нам о страшных голодных годах.

*Со слов Мансуровой Халимы Лотфулловны записала библиотекарь Куземьяровской сельской библиотеки Уразова Айгюль Гаптелмазитовна (2013 г.)*

## “Фәйзер кабер”

Яматай авылдан Байавылга килгәндә, авылга кергәндә сул якта ялгыз чыршы үсеп утыра. Бу урынны “Фәйзер кабер” дип атыйлар, аның белән рәттән зур чокыр бар. Тракторчы Фәйзер тракторы белән капланып шул чокырга караңгыда (төнлә эшләгәндә) барып төшеп үлгән.

Бу урынны ияле дип сөйлиләр. Бераз әче бал эчеп алган хатын-кыз күрше авылдан 8 литрлы чәйнеккә әче бал салып алып ат белән кайтып килгәндә, Фәйзер кабердән ап-ак киемдә озын гына бер ир кеше чыгып, атның дилбегәсеннән тотып атны туктата. Атны күпме кусаң да, беркая да бармый, тик тора. Хатын-кыз катып кала. Белгән догаларын укып, әче балын түккәч, атны озын акка киенгән кеше җибәрә.

Өлкәннәр: “Зират яныннан үткәндә, айнык һәм тәһарәт белән йөрергә, узып барганда белгән догаларңны укып, әрвахлар рухына багышларга кирәк”,- дип белми генә әйтмәгәннәр инде.

*Шарипова Гөлзинә Хаким кызы сүзләреннән  Уразова Айгюль  Гаптелмәҗит  кызы язып алды. 2013 ел.*

## “Могила Файзыра”

Когда едешь от Чувашаево в Куземьярово, при въезде в село слева растет одинокая ель. Это место называют “Могила Файзыра”. Рядом  – большая яма. Во время ночной смены вместе с трактором Файзыр упал в эту яму и погиб.

Говорят, здесь есть приведение. Как-то из соседней деревни чуть подвыпившая женщина с восемью литрами бражки ехала мимо, из могилы Файзыра вышел высокий мужчина в белой одежде и остановил лошадь, схватившись за узцы.Сколько она не понукала лошадь, та стояла как вкопанная. Женщина остолбенела. Прочитала все известные молитвы, вылила бражку и тогда мужчина в белых одеждах отпустил лошадь.

Не зря старики говорят: когда проезжаешь мимо кладбища, нужно быть трезвым, чистым и читать молитвы в память ушедших в мир иной.

*Со слов Шариповой Гульзины Хакимовны записала библиотекарь Куземьяровской библиотеки Уразова Айгюль  Гаптельмазитовна. 2013 г.*

## Туган ягым, туган авылым !

Туган ягым, туган авыл, туган җирем
Һәр кешенең туган нигезе.
Нәрсә бар соң шуннан газизерәк ?
Ниләр бар соң шуннан кадерде ?

Туып үстем Әрҗән авылында
Шаулы Тол елгасы буенда.
Челтерәп аккан чишмә суын эчеп,
Хозурланып яшим мин монда.

Табигате матур Әрҗәнемнең
Урманнарга баө ул, кырларга,
Казган тавы үзе ни тора,
Юктыр бер тау андый районда.

Бишембайда, Очлы тауда үсә
Җир җиләге, шартламасы да
Чия тауда пешә чияләр
Күпме җыяласың җый гына.

Тол буенда пешә бөрлегәннәр,
Шомыртлары, балан, миләшләр.
Гөмбәләре һәрбер куак саен
Ә дигәнче тула кәрзиннәр.

Сөйләп бетергесез матур авылым
Кешеләре аның ягымлы.
Тик шатланып искә алырмын мин
Анда үткән сабый чагымны.

Яшим авылымда Һәм яшәрмен
Китсәм дә мин китмәм озаккка
Без Әрҗәннең якты киләчәге,
Таянычы булыйк Һәрчакта !

*Стихи Рангуловой Алины Ринатовны.*

**Река Тулва – пермская Хуанхэ!**

В Китае есть знаменитая река Хуанхэ, что в переводе означает “Желтая река”. Река получила свое название из-за того, что ее воды размывают собственные берега и несут огромное количество твердого взвешанного мальтериала по направлению к морю. Когда Хуанхэ впадает в море, ее “желтый” след продолжается в нем на сотни километров, это видно даже из космоса. Гидрологи утверждают, что Хуанхэ обладает самым большим твердым стоком в мире. Ежегодно она выносит в море 1,3 миллиарда тонн твердых взвешенных наносов – размытых горных пород! Поэтому и море, в которое впадает река, тоже назвали Желтым. В долине этой великой реки когда сформировался китайский этнос...

... Оказывается, в Пермском крае есть своя “Хуанхэ”. Это река Тулва, которая начинается на юге Прикамья в Уинском районе, на юге Тулвинской возвышенности, и впадает в Каму в районе города Оса. Река необычайно петляет и переносит огромное количество размытого рыхлого материала, заиливая скважины и местные насосы для воды по ходу своего течения. В переводе с мансийского слово “туль “ – “туман” , значит название реки – “туманная река” (или “ река с мутной водой”). Конечно, пермская “Хуанхэ” значительно уступает китайской сестре, но особенно весной ее воды необычайно мутны от огромного количества переносимых глинистых частиц. Например, у деревни Красный Яр скорость размыва береговой линии достигает полметра в год!

Тулва интереснейший природный объект. Все отечественные и даже зарубежные ученые гидрологи мечтают увидеть Тулву – пермскую Хуанхэ...

*Место происхождения легенды: Уинский район Пермского края, река Тулва и ее “твердый сток”, научные работы гидрологов*

Библиография: Ширинкин П.С. Книга легенд.Туристические легенды Пермского края.- Пермь, 2013.- С.56-57.

СОДЕРЖАНИЕ

**“Ак чишмә” ( суык чишмә)**

**“Белый родник”(холодный родник)**

**Аклыш авылым тарихы**

**История села Аклуши**

**“Алтын кәмә тавы”**

**Гора “Золотая лодка”**

**“Алтын үрдәк”**

**“Золотая утка”**

**Байавыл турында легенда**

**Легенда о Куземьярове**

**“Җиде газизлар”**

**“Семь святых”**

**Каенавыл чишмәләре**

**Березниковские ручьи**

**Легенда о “Лешачьей” горе**

**История Бичуринского поселения в названиях**

**“Мир болын кысык ”**

**“Мировая поляна”**

**“Сәфәр-багырь”**

**“Сафар”**

**Султанай алыплары**

**Султанаевские великаны**

**“Тәкә тау”**

**“Баранья гора”**

**Түбән авыл**

**История Ишимово в названиях**

**“Түмәлчәк тау”**

**“Круглая гора”**

**“Фәйзер кәбер”**

**“Могила Файзера”**

**Туган ягым, туган авылым**

**Река Тулва – пермская Хуанхэ**

ГЕОГРАФИЧЕСКИЙ УКАЗАТЕЛЬ

**Березники:**
Березниковские ручьи
**Бичурино:**
История Бичуринского поселения в названиях
**Ишимово:**
История Ишимово в названиях
**Краснояр:**
Туган ягым, туган авылым
**Куземьярово:**
Байавыл турында легенда
Легенда о Куземьярове
“Җиде газизлар”
“Семь святых”
“Түмәлчәк тау”
“Круглая гора”
“Фәйзер кәбер”
“Могила Файзера”
**Новый Ашап:**
“Мир болын кысык ”

“Мировая поляна”
“Сәфәр-багырь”
“Сафар”
**Река Тулва**
Река Тулва – пермская Хуанхэ
**Сараши:**
“Җиде газизлар”
“Семь святых”
**Султанай** :
“Ак чишмә” ( суык чишмә)
“Белый родник”(холодный родник)
“Алтын үрдәк”
“Золотая утка”
Султанай алыплары
Султанаевские великаны
**Сюзянь** :
“Алтын кәмә тавы”
Гора “Золотая лодка”